Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Иске Михайловка авыл җирлеге Юкәле авылында гражданнарның җыены
нәтиҗәләре турындагы карар

25 ноябрь 2022 ел № 3

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Михайловка авыл җирлеге Уставының 13.1 статьясы, «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Михайловка авыл җирлегенең Юкәле авылында гражданнар җыены йомгаклары буенча тавыш бирү нәтиҗәләре турында»2022 елның 25 ноябрендәге хисап комиссиясе беркетмәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Михайловка авыл җирлегенең Юкале авылында гражданнар җыены карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Михайловка авыл җирлегенең Юкәле авылында 2022 елның 25 ноябрендә гражданнар җыены узмаган дип танырга.

2.Әлеге карарны«Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга,Юкәле авылы, Речная урамы, 9 йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында халыкка игълан итәргә,шулай ук «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайты «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче Н.А.Миназева